**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 10 октябрендәге 4302 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 3 июлендәге 2841 номерлы «2024 елда “Казан шәһәрен үстерү институты” муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан эшләрне башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнарны раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2010 елның 19 ноябрендәге 10406 номерлы «Казан шәһәре муниципаль учреждениеләренә карата муниципаль бирем формалаштыру һәм муниципаль биремне үтәүне финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында»гы, 2021 елның 3 ноябрендәге 2906 номерлы «“Шәһәрне үстерү институты” муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан эшләрне башкаруга (хезмәт күрсәтүгә) норматив чыгымнарны билгеләү тәртибен раслау турында»гы карарлары нигезендә **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 3 июлендәге 2841 номерлы «2024 елда “Казан шәһәрен үстерү институты” муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан эшләрне башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнарны раслау турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктта «2024 елга» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. кушымтаны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.3. әлеге карарның кушымтасын 2024 елның 3 июлендәге 2841 номерлы карарга кушымта дип санарга.

2. Кертелгән үзгәрешләр 2024 елның 2 маеннан алып барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга һәм аны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 10 октябрендәге 4302 номерлы карарына кушымта

**«Казан шәһәрен үстерү институты»**
**муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан**
**эшләрне башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә)**
**норматив чыгымнар**

| **№ т/б** | **Муниципаль эшнең (хезмәтнең) исеме** | **Муниципаль эшнең (хезмәтнең) эчтәлеге** | **Норматив чыгымнар (сум елга)** |
|---|---|---|---|
| 1 | Территорияләрне планлаштыру буенча документлар әзерләү | Территорияне планлаштыру проектын әзерләү | 32 636 003,65 |
| | | Территорияне ызанлау проектын әзерләү | 7 053 027,34 |
| 2 | Җир кишәрлекләренең һәм күчемсез милек объектларының шәһәр төзелеше документларына туры килү-килмәвен тикшерү һәм өйрәнү | Җир кишәрлекләренең һәм күчемсез милек объектларының шәһәр төзелеше документларына туры килү-килмәвен тикшерү һәм өйрәнү | 5 280 450,00 |
| 3 | Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү өчен документлар әзерләү | Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү өчен документлар әзерләү | 11 252 220,00 |
| 4 | Кадастр эшчәнлеген башкару | Дәүләт кадастр исәбен башкару өчен кирәкле мәгълүматларны эченә алган документларны әзерләү өлешендә күчемсез милеккә карата эшләр башкару | 6 438 660,20 |
| 5 | Эшчәнлекне административ яктан | Проектлар белән идарә итү | 63 332 395,81 |
| | | Анализ ясау | 24 769 177,70 |

| № т/б | Муниципаль эшнең (хезмәтнең) исеме | Муниципаль эшнең (хезмәтнең) эчтәлеге | Норматив чыгымнар (сум елга) |
|---|---|---|---|
| | тәэмин итү | Мониторинг үткәрү | 10 518 927,80 |
| 6 | Архитектура-төзелеш буенча проектлаштыруны башкару | Күчемсез милек объектларының проект-смета документларын эшләү | 77 040 237,50 |